КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 март г.Казань № 163

2018 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантлары күләмнәре турында

Татарстан Республикасы Президентының «2018 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында» 2018 ел, 9 февраль, ПУ-155 нче Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елда мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президентының түбәндәге грантларын (алга таба – грантлар) билгеләргә:

«Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесенә «Татар опера һәм балет театрын дөньякүләм музыкаль киңлеккә интеграцияләүнең яңа этабы: дөньякүләм һәм милли музыкаль театр шедеврларын популярлаштыру, матди-техник базаны яңарту һәм ныгыту, халыкара фестивальләр, гастрольләр һәм проектлар үткәрү, театр спектакльләрен тудыру һәм аларда катнашу өчен сәхнә осталарын чакыру» проекты өчен – 155 800,0 мең сум;

«Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенә «Иҗади проектларны тормышка ашыруда инновацион якын килү, Россия һәм чит ил татарларын театр хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү, матди-техник базаны яңарту һәм ныгыту, хәзерге заман татар драматургиясен һәм мәдәниятен популярлаштыру, Россия һәм ерак чит илләрнең төп театр коллективлары белән иҗади тәҗрибә алмашу» проекты өчен – 36 360,0 мең сум;

«В.И.Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Дөнья әдәбияты әсәрләре буенча спектакльләр кую, театр сәнгатен пропагандалауга юнәлдерелгән иҗади проектларны тормышка ашыру, Россия һәм ерак чит илләрнең театр коллективлары белән тәҗрибә алмашу» проекты өчен – 26 360,0 мең сум;

«Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Коллективның иҗади потенциалына ярдәм күрсәтү, матди-техник базаны яңарту һәм ныгыту, милли сәнгатьне популярлаштыру, саклап калу һәм үстерү» проекты өчен – 9 601,8 мең сум;

«Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә «Музыка һәм сүз сәнгате аша балалар һәм өлкәннәр аудиториясен җәлеп итү һәм тәрбияләүнең дөньякүләм уңай тәҗрибәсе буларак концертларның филармония абонемент системасын эшләү, үстерү һәм пропагандалау» проекты өчен – 8 798,0 мең сум, «Дөнья халыкларының музыкаль мәдәниятләре һәм традицияләре синтезы буларак джаз» проекты өчен – 8 400,0 мең сум, «Татар музыкаль фольклорын тикшерү, пропагандалау һәм сәхнәдә бирү аша Россия һәм дөнья халыклары музыкаль мәдәниятенә интеграцияләү» проекты өчен – 6 700,0 мең сум, «Халыкныкы – халыкка: Россия һәм дөньякүләм танылган вокаль, инструменталь башкаручыларын, коллективларын җәлеп итү аша халык һәм дөнья классик сәнгате шедеврларын саклап калу, популярлаштыру һәм пропагандалау, Россия, чит ил шәһәрләре буенча гастроль турларын оештыру, конкурслар, фестивальләр үткәрү, коллективның матди-техник базасын стимуллаштыру, яңарту һәм ныгыту» проекты өчен – 4 634,4 мең сум;

«Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенә «Россия һәм дөньякүләм танылган башкаручыларын һәм дирижерларын җәлеп итү һәм осталыкны үстерү» проекты өчен – 12 720,0 мең сум;

«Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Ислам дөньясының яңа киносы чагылышы буларак Казан халыкара мөселман киносы фестивале» проекты өчен – 1 929,2 мең сум;

«Бәрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Керәшеннәрнең этник музыкаль мәдәнияте һәм милли традицияләренең иң яхшы үрнәкләрен торгызу, саклап калу, үстерү һәм пропагандалау» проекты өчен – 2 601,2 мең сум.

2. 2018 елда грантларны түләү өчен 273 907,6 мең сум күләмендәге чыгымнар «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 ел, 30 ноябрь, ТРЗ-95 нче Татарстан Республикасы Законында «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы» ведомствосы буенча әлеге максатларга каралган акча исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына:

бер ай эчендә грант алучыларның грантлар түләүгә бүлеп бирелгән акчаны максатчан файдалану һәм иҗади эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисаплар бирү тәртибен һәм вакытларын билгеләргә;

2019 елның 1 мартына кадәр 2018 елда грантларны максатчан файдалану турындагы хисапны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин